# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Ковали торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**2023 елның 18 ноябре** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Ковали торак пунктында гражданнар җыены **карар кабул итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Ковали торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, инерт материаллары сатып алу, шул исәптән объектларны техник паспортлаштыру;

2. территориянең тышкы төзекләндерү объектларын төзү һәм ремонтлау (зиратны әйләндереп алу, контейнер мәйданчыклары төзү), шул исәптән бу максатлар өчен төзелеш материаллары һәм контейнерлар сатып алу;

3. смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнаштырарга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зеленодольск муниципаль районы
Бишнә авыл җирлеге башлыгы: И. М.Фатхуллин